СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 13 » ноябрь 2019 ел** **№ 283**

**Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Арча муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чоры бюджетларыннан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk/tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә.

Арча муниципаль район башлыгы,
район Советы рәисе

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

И.Г.Нуриев

Арча район Советының
2019 елның "13"ноябрь
№283 номерлы карарына
кушымта

**Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) торган башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләре**

1. Әлеге кагыйдәләр Арча муниципаль районы җирлекләре бюджетларына Арча муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы күрсәткечләренә ирешүгә һәм (яки) аларны бүләкләү, җирлек халкының тормыш сыйфатын яхшырту максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләргә грантлар бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) акчалары исәбеннән бирелә.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче булып «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ (алга таба – финанс органы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга финанс органына билгеләнгән тәртиптә бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Башка бюджетара трансфертлар конкурс җиңүчеләре дип табылган, эшчәнлек нәтиҗәлелегендә иң югары бәяләр алган җирлекләр бюджетларына бирелә (алга таба-конкурс).

7. Башка бюджетара трансфертлар җирлекләрнең тормыш-көнкүрешен турыдан-туры тәэмин итүче объектларының матди-техник базасын ныгытуга, социаль инфраструктура объектларын төзекләндерүгә һәм җирлекләрнең социаль-әһәмиятле башка мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелә.

8. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге критерийларга җавап бирә торган җирлекләр бюджетларына бирелә:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселогы нигезендә төзелгән авыл җирлекләренә һәм шәһәр җирлекләренә грантлар турында" 2013 елның 29 августындагы 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләренә

грантлар бирү һәм файдалануга башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләренең 4.2 пунктлары нигезендә, территориясендә сайлап алу узган җирлекләр булу;

б) Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза булу.

9. Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 12 пункты нигезендә башка бюджетара трансферлар бирү турында килешү төзү;

б) җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын үтәү;

в) Арча муниципаль районы башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән грантлар түләү гамәлгә ашырыла торган җирлекләр исемлеген раслау турында боерыгы булу.

10. Җирлек башкарма комитеты (алга таба - вәкаләтле орган), башка бюджетара трансфертлар алу өчен, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән вакытта түбәндәге документларны Башкарма комитетка тапшыра:

Башкарма комитет тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансферлар бирүгә гариза һәм чыгым йөкләмәсенең барлыкка килүен раслый торган башка документлар.

11. I-җирлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$VMT_i = \frac{VMT}{K}$$

биредә:

VMTi - i-җирлегенә башка бюджетара трансферт күләме, сум;

VMT - Арча муниципаль районы бюджетына кергән башка бюджетара трансферт күләме;

K-конкурста җиңүчеләр дип танылган җирлекләр саны.

12. Башка бюджетара трансфертларны бирү Башкарма комитет һәм вәкаләтле орган арасында Башкарма комитет тарафыннан расланган формалар нигезендә төзелә торган башка бюджетара трансфертларны бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшыру сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны алучының килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

14. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып җирлекләргә түләнгән грантлар саны тора.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү, вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган хисап анализы нигезендә, Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

15. Вәкаләтле органнар, килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча, башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны район Башкарма комитетына тапшыралар.

16. Район Башкарма комитетына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык вәкаләтле органга йөкләнә.

17. Башка бюджетара трансфертлар финанс органы тарафыннан җирлекләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган территориаль органнары счетларына күчерелә.

18. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

19. Башка бюджетара трансфертларны биргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Арча муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

22. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе контрольдә тота.